Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № №XIX-8**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 29 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.10.2014 ел, №199пи карары белән расланган "2014-2018 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында туризмны үстерү" муниципаль программасын тормышка ашыруның барышы турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.10.2014 ел, №199пи карары белән расланган “2014-2018 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында туризмны үстерү” муниципаль программасын тормышка ашыруның барышы турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Докладчыларның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.10.2014 ел, №199пи (алга таба-муниципаль программа) карары белән расланган “2014-2018 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында туризмны үстерү” муниципаль программасын тормышка ашыруның барышын канәгатьләнерлек дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге белән берлектә йөкләргә:

3.1) муниципаль программа чараларына аны актуальләштерүгә юнәлдерелгән тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә;

3.2) Татарстан Республикасының туризм буенча дәүләт комитеты белән берлектә 2017-2018 елларда муниципаль программаны гамәлгә ашыруны җаваплы башкаручылар тарафыннан тулы күләмдә тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының финанс-бюджет палатасына, әлеге максатларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган мөмкинлекләрне һәм чараларны исәпкә алып, муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга финанс чаралары бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

5. Транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык, социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт, бюджет, финанс, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими

комиссияләргә үз юнәлешләре буенча муниципаль программаның үтәлешен контрольдә тотарга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы урынбасары И.Г. Ибраһимовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев